# КАРАР

**“09” ноябрь 2021 ел № 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,2021 елның 09 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Яңа Иябаш авылында халыкны өзлексез чиста су белән тәэмин итү өчен, су башнясына насос сатып алу һәм гамәлдәге су системасына тоташтыру.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 273 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 156 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 149 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Яңа Иябаш авылында халыкны өзлексез чиста су белән тәэмин итү өчен, су башнясына насос сатып алу һәм гамәлдәге су системасына тоташтыру.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңа Иябаш авылы, Төхвәтуллин урамы, 8а йорты

адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров